ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.10.2022 г. Казань № 198-20/тэ-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

«Куйбышев-Затон коммуналь челтәрләре» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү буенча эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыруны туктатуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 2022 елның 12 октябрендәге 31-ПР номерлы беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Куйбышев-Затон коммуналь челтәрләре» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 05.12.2018 №5-63/тэ;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 05.12.2018 №5-63/тэ карары белән «Куйбышев-Затон коммуналь челтәрләре» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2020 елга төзәтмә кертү турында» 27.11.2019 №5-56/тэ;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 05.12.2018 №5-63/тэ карары белән «Куйбышев-Затон коммуналь челтәрләре» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2021 елга төзәтмә кертү турында» 05.11.2020 №155-12/тэ-2020;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 05.12.2018 №5-63/тэ карары белән «Куйбышев-Затон коммуналь челтәрләре» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә)

билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 елга төзәтмә кертү турында» 12.11.2021 №253-40/тэ-2021;

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев